

Ковылкино районында зур спорт вакыйгасы – Куняшевлар призына футбол буенча 20 нче юбилей ачык турнир шәһәр ФОКында һәм Кочелаево авылы спорт сарае базасында узган.
Ковылкино районда Куняшевлар династиясе футбол vсешенә зур олеш кертvләре билгеле. Алар исемендәге турнир ике дистә ел дәвамында футбол соючеләрне берләштерә торган, сәламәт яшәv рәвешен, гаилә спортын пропагандалаучы яхшы спорт традициясен дәвам иттерә.      Узган турнирда Мордовия һәм Пенза олкәсеннән 14 команда катнашкан. Турнир ике лига буенча уздырыла һәм торле милләт вәкилләрен берләштерә.
Комеш лигада Инсар командасы жинv яулый, Пензадан килгән кондәшләрен 2-1 исәбе белән жинә. Алтын лигада Самаевкадан “Небо” хәрбиләр командасын жинеп, ике жавапсыз туп кертә. Нәкъ менә алар топ алтын кубок ияләре булганнар. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, Ковылкиноныын футбол тормышын Куняшевлар гаиләсе вәкилләреннән башка кvз алдына китерv момкин тvгел. Алар дистә еллар дәвамында республика һәм хәтта Россия футбол ареналарында шәһәр намусын яклаганнар. Абыйларынын олысы, Анатолий Джарулла улы Куняшев, футбол озак уйнамый, ләкин соныннан vзен искиткеч тренер буларак кvрсәтә. Ә житмешенче елларда шәһәрнен футбол союческәре Рифат белән Рафик Куняшевлар исемнәре белән бәйлиләр. Ләкин Ковылкиннын футбол тормышынын чын пигы - узган гасырнын 80-90 еллары. Ул елларда “Спартак” Россия дәрәжәсенә чыга һәм физкультура коллективлары арасында Россия беренчелегендә чыгыш ясый башлый. Нәкъ шул вакытта Шәймәрдән белән Евгений Куняшевларнын гаилә таланты тулысынча ачыла. Ә ин югары нәтижәләргә ул вакытта “Спартак” тренеры Анатолий Куняшев булганда ирешә. Берничә ел дәвамында нәкъ Куняшевлар Ковылкиннын “Спартак” командасын жинvгә алып бара. Биш дус абый vз гомерләренен бер олешен Ковылкино футболына бирә. Куняшевлар абыйларынын ин тугры һәм шул ук вакытта ин каты жанатарлары - аларнын әтиләре Джарулла Йосып улы була. Уеннарда жинелгәннән сон ул беркайчан да ботен команданы яки судьяларны котмәгән, ә балаларына искәрмәләр беренче буларак ясаган. Футбол белән Куняшевларнын балалары, оныклары мавыга, алар гаиләнен олкән вәкилләренен лаеклы иярченнәре булалар.
Ковылкинлылар дистә еллар дә-вамында салынган футбол тради-цияләрен саклыйлар. Куняшевлар династиясе, элеккечә, районда һәм республикада бу спорт торен популярлаштыруга зур олеш кертә.

**Н.ХӘЛИЛ**